Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

бسم الله الرحمن الرحيم

# Ислам Нуры

№ 5 (633) 20 март, 2017 ел (1438, Җөмәдел-ахир) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

## Балалар хажга сәяхәт ясады







5 мартта Чаллы мөхтәсибәте каршындагы “Хәзинә” клубында дини гыйлем алучы балаларның (җитәкчесе Ләйсән Әхмәтшина) “Нур-Ихлас” мәчетендә “Хажга сәяхәт” бәйрәме узды. Башта балалар самолетта изге Мәккә шәһәренә очтылар. Самолетта аларга Изге Мәккә шәһәре һәм Хаҗ гыйбадәте турында видеофильм күрсәтелде. Аннары балалар кунакханәгә урнашты, биредә тамак ялгады. Малайлар госел коенып ихрамга керделәр. Хаҗ төркемен шәһәрнең “Ихлас” мәчете имамы Илгиз хәзрәт Әшрәпов җитәкләде. Аның җитәкчелегендә балалар тәваф кылды, ике рәкәгать доха намазы укыды, зәм-зәм суы эчте, сәгый кылды. Балалар Гарәфәт тавы макетына килеп анда дога-теләкләрен язган кәгазь кисәкләрен ябыштырып калдырдылар. Мөздәлифә үзәнлегендә таш җыйгач, Минага килеп шайтанга таш ату, корбан чалу йолаларын үтәделәр һәм чәчләрен кыскартып ихрамнан чыктылар. Соңыннан хаҗны белү буенча викторина үткәрелде, балаларга Кәгъбәтуллаһ макеты ясалган сувенирлар бүләк ителде, алар тәмле пицца белән сыйландылар.

Бәйрәмдә йөзгә якын бала катнашты. Клуб җитәкчесе Ләйсән ханым әйтүенчә, мондый чаралар Чаллы мәчетләрендә инде берничә ел үткәрелә.

**Рәсемнәрдә:** бәйрәмнән күренешләр.

## Мәчет Коръән бәйгесе уздырды

23 февральдә Чаллының “Тәүбә” мәчете балалар арасында Коръән уку бәйгесе уздырды. Анда 150 бала катнашты. Аларның һәркайсы аерым призга һәм Мактау кәгазенә ия булды. Бәйге катнашучылар “Тәүбә” мәчетенең якшәмбе мәктәбе укучылары һәм Түбән Кама шәһәре вәкилләре иде. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар төркемендә Чаллыдан Инсаф Шәрипҗанов, Кәримә Нәҗипова, Мөхәммәд Ибраһимов җинделәр. 7-9 яшьлек малайлар арасында иң яхшы нәтиҗәне Чаллыдан Наил Зубарев, Түбән Камадан Йосыф Галиев, Чаллыдан Гомәр Хәкимов күрсәттеләр. Ә 9-14 яшьлекләр арасында Түбән Камадан Әмин Шәйдуллов, Чаллыдан Ибраһим Гомәров, Түбән Камадан Рәсүл Миннебаев иң көчлеләр булып танылды.

6-9 яшьлек кызлар арасында җиңүчеләр булып Түбән Камадан Әмирә Хисмәтуллина, Самирә Газизҗанова, Чаллыдан Әминә Солтанова чыктылар. 10-15 яшьлек кызлар арасында иң югары баллга Чаллыдан Мәрьям Хаҗиева, Түбән Камадан Зәйнәб Хәйретдинова, Амалия Шәйдуллова ирештеләр.

Җиңүчеләр 22 мартта Чаллыда республика күләмендә узачак бәйгедә катнашачак.



**Рәсемдә:** бәйгедән күренеш.

«Утверждаю»
Председатель ЦРО – ДУМ РТ, Муфтий
Камил хазрат Самигуллин

**Положение**
**IX объединенного турнира мусульманской молодежи по татарской борьбе «Көрәш» и армспорту на кубок ЦРО – ДУМ РТ**

**1. Цели и задачи:**
- популяризация национальной борьбы и армспорта среди мусульманской молодежи для привлечения их к более активной жизни, воспитание у них выносливости и терпения;
- укрепление дружественных связей среди мусульманской молодежи, любящей спорт.

**2. Сроки и место проведения соревнований:**
- соревнования проводятся 09 апреля 2017 года в спорткомплексе “Витязь” г.Наб. Челны (ул. Мусы Джалиля, 23, ост. Челныгорстрой”, тел.8(8552) 56-65-99);
- соревнования лично-командные, проводятся по олимпийской системе;
- взвешивание участников с 08.00 до 09.00
- совещание представителей и судей с 09.00 до 9.30;
- предварительные схватки 09.30
- открытие соревнований в 11.00

**3. Руководство проведением соревнований:**
- общее руководство подготовкой и проведением соревнований осуществляет Духовное управление мусульман РТ и мухтасибат г. Наб.Челны. Главный судья соревнований – главный казый Духовного управления мусульман РТ Джалиль хазрат Фазлыев.
- непосредственное руководство соревнований возлагается на судейскую коллегию.

**4. Участники соревнований и условия проведения:**
- к соревнованиям допускаются мусульмане не младше 18 лет, ***читающие намаз,*** имеющие соответствующею физическую подготовку и медицинский допуск;
- весовые категории по борьбе: 60; 70; 80; 90; 100 и свыше 100 кг.
- весовые категороии по армспорту: до 70 кг.; 85; свыше 85 кг.
- до взвешивания участники должны ***пройти тест по знанию правил чтения намаза;***
- ***соревнования проходят согласно*** **жеребьевки**;
- допуск до участия в соревнованиях только в спортивной форме и тюбетейке.

**5. Награждение:**
- победители в каждой весовой категории награждаются дипломами и денежными призами;
- команда-победитель – Кубком;
- ***среди завоевавших первое место в своих весовых категориях проводится жеребьевка и выигравшему вручается самый ценный приз турнира – путевка в Хадж.***

**6. Финансовые расходы:**
- все расходы, связанные с подготовкой и проведением турнира, награждением победителей - за счет организаторов турнира;
- расходы по командированию на соревнование спортсменов, судей, тренеров (проезд, питание, размещение) несут командирующие организации.

**7. Заявки:**
- заявки, заверенные врачом и командирующей организацией, подаются в судейскую коллегию 09 апреля 2017 года при взвешивании;
- каждый участник при взвешивании должен предъявить паспорт.

## Мөселман яшьләренең татарча һәм кул көрәше буенча IX Берләштерелгән турниры

Ул быел 9 апрельдә һәр елдагыча Чаллының “Витязь” спорткомплексында узачак. Узган ел татарча көрәштә һәм кул көрәшендә җөмһүриятебезнең 20 шәһәр районыннан һәм Башкортостаннан 81 мөселман спортчысы, шул исәптән танылган 12 спорт мастеры көч сынашкан иде. Ә бу ярышларның нинди дәрәҗәдә узуын ачык күрсәтә. Турнирда фәкать намаз укучылар гына катнаша ала. Шуңа күрә алар башта намаз гыйбадәтен белү буенча әңгәмә узалар. Турнир ахырында үз төркемнәрендә җиңүчеләр арасында шобага салу уздырыла һәм анда җиңүче турнирның иң олы бүләге - Олуг хаҗга Юллама белән бүләкләнә. Быелтыр мондый бәхет Әлмәт районы вәкиле спорт мастеры Руслан Нургалиевка елмайды. Ә калган җиңүчеләргә акчалата призлар тапшырыла. Ә җиңүче команда УДО — Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте кубогына ия була. Быелтыр аны Балтач районы командасы яулады.

Турнирда Татарстаннан читтәге төбәкләрдән дә мөселман спортчылары башкалар белән тигез шартларда көч сынаша ала. Рәхим итегез!

# Йакуб галәйһи сәлләмнең васыяте

**Ислам динендәге олуг пәйгамбәрләрнең берсе турында сөйләргә телим. Ул үзе пәйгамбәр, аның атасы да, бабасы да пәйгамбәр булган, хәтта аның баласы да пәйгамбәр. Бу - Йакуб галәйһи сәлләм. Ибраһим пәйгамбәрнең оныгы, Исхак пәйгамбәрнең улы, аның улы Йосыф галәйһи сәлләм дә зур дәрәҗәле пәйгамбәрләрнең берсе.**

Төгәлрәге, без Йакуб галәйһи сәлләмнең үләр алдыннан әйткән васыятен искә төшерербез.

Күз алдына китереп карагыз: пәйгамбәрнең соңгы мизгелләре, ул үлем түшәгендә ята. Аталары балаларын, оныкларын калдырып, бу дөнья белән хушлаша. Шуннан соң ул аларның берсен дә күрмәячәк, чөнки ул бу дөньядан мәңгегә китә. Әлбәттә, бу минутларны һәр кеше авыр кичерә. Әҗәле килеп җиткәч, кеше үзеннән башка кеше турында уйлый микән? Әмма Йакубны моннан да мөһимрәк нәрсә борчый.

Сез ничек уйлыйсыз, гомеренең ахыргы минутларында нәрсә борчый аны? Ни өчен кайгыра ул? **Балалары аның малын ничек бүлерләр, нинди акчага яшәрләр, ничек көн күрерләр дип борчыламы? Юк! Аны күпкә җитдирәк сорау борчый. Йакуб үлгәннән соң диннәрен саклап кала алырлармы балалары?**

Бу дөньяны калдырып киткәнче, ул балаларының, оныкларының, нәселенең диннәрен саклап калуларына, Аллаһы Тәгалә динендә ныклы булачакларына ышанасы килә. Ул бу дөньяны тыныч күңел белән калдырырга тели, йөрәген җылытырдай сүзләр ишетәсе килә аның. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

“Әллә сез Йакубка үлем ирешкәндә аның янында идегезме? Ул улларыннан, борчылып: “Миннән соң сез кемгә табыначаксыз?”- дип сорый”.

**Аны мөлкәте кемгә калуы, ничек итеп аның мирасын бүлүләре борчымый. Аның нәселенең дөньяга дөрес караштa булачакларына, үзе үлгәннән соң да диннәрен саклап кала алуларына, бернинди ширк кертмичә, бер Аллаһка гыйбадәт кылуларына ышанасы килә. Аның өчен улларының дөрес диндә булуы, ни дәрәҗәдә Аллаһы Тәгалә белән улларының калебләре бәйләнгәнлеге мөһимрәк. Ни дип җавап бирә соң аның балалары? Нинди җавап ишетә соң ул алардан? Үз өсләренә шундый зур җаваплылыкны алырлармы алар?**

**Балалары аталарына: “Бары бер Аллаһка гына гыйбадәт кылачакбыз! Синең диннән тайпылмаячакбыз!” - дип җавап биргәч кенә тынычлана атаның күңеле.**

Улларыннан юктан Бар итүче бер Аллаһка ышаначакларын, бер Аңа гыйбадәт кылачакларын һәм мөселман булып калачакларын ишеткәч кенә тынычлана аның күңеле.

Аллаһы Тәгалә бу турыда болай дип әйтә: **“Алар: “Без бары бер Аллаһка гына гыйбадәт итәчәкбез,** синең атаңнар: Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак гыйбадәт кылган бер Аллаһка гына гыйбадәт кылачакбыз. Бер Аңа без буйсынабыз!”- дип җавап бирәләр.

Йакуб балаларының диннәрен белүләрен, аны саклап калачакларын күреп сөенә. Ни өченме? Чөнки аны бары бер сорау борчый - балалары алдында бурычын үти алдымы ул, алар туры юлны калдырмаслармы?

Галимнәрнең берсе: “Әгәр сез миннән кечкенә бер кәгазь кисәгендә бөтен Ислам дөньясы өчен нәсихәт язып калдырырга кушсагыз, һәм анда бары бер җөмлә язып калдырып була торган булса, мин: “Миннән соң кемгә табыначаксыз?” дип язып калдырыр идем,”- ди. Һәр мөселман гомере буе уйлансын, калебен тикшерсен. Бабайлары мирас итеп калдырган, алардан алда сәхәбәләр саклаган һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм амәнәт итеп калдырган динен саклыймы ул? Һәм аннан соң калган балаларына бер Аллаһка гыйбадәт кылучы мөселман булырга кирәклеген төшендерә, туры диннән тайпылмаслык итеп гыйлем бирә алганмы? Аталары үлгәннән соң диннәрен калдырып, туры юлдан тайпылып юкка чыкмаслармы алар?

Җәмәгать, безнең дә балаларыбызга соңгы васыятебез Йакубныкы кебек булырмы? Аларның җавабы йөрәкләребезне җылытырмы? Җавапларын ишетеп, Йакуб сөенгән кебек, без дә шатлана алырлык сүзләр ишетә алырбызмы? Аларның җаваплары бездән тора. Тиешле дини тәрбия бирә алдыкмы без аларга?

**Әлхәмделилләһ, күпләребез төрле сынаулар килүгә карамастан, намаз укый, авырлыкларга карамыйча, тырышып, Аллаһ ризалыгы өчен ураза тота. Әле күптән түгел генә “лә иләһә иллә Аллаһ” кәлимәсенең ни аңлатканын да белмәгәннәр бүген кычкырып, аңлап, матур итеп Коръән укый! Ә бит үз динеңне тотуның ләззәтен, үз динеңдә ныклы булырга кирәклекне киләсе буыннарга җиткерү бик мөһим! Моның өчен бик тырышырга кирәк.**

Сүзләремне дәлилләп, Аллаһы Тәгаләнең динен тотучыларның батырлыгы, кыюлыгы, **диннәрендә нык торулары** ачык күренгән бер вакыйганы сөйләсем килә. Җәмәгать, һәр вакыйгада Аллаһның хикмәте бар.

Тарихтан билгеле булганча, Явыз Иван Казанны яулап алганнан соң көчләп, мәҗбүри чукындыру башлана. Кемнәрдер, дөнья малына кызыгып, диннәрен саталар. **Күпләр ата-аналарыннан калган диннәрен саклап калыр өчен, туган туфракларын, гомере буе тир түгеп, тырышып-тырмашып, бер ял белмичә туплаган хәләл малларын, туган җирләрен, газиз йортларын, мал-мөлкәтләрен ташлап, яланаяк, яланөс, бер ризыксыз, зур нужалар күреп, күз күрмәгән, колак ишетмәгән, бер дә белмәгән якларга чыгып китәргә мәҗбүр булалар. Ни өчен мондый авыр юлны сайлый соң алар? Бары тик Исламда калу өчен, бары тик аларның диннәренә тимәсеннәр, бары тик диннәрен саклап кала алсыннар өчен.** Чөнки алар аталары калдырган васыятькә тугры: “Миннән соң сез кемгә табыначаксыз?”

Аталарына биргән вәгъдәләренә тугры калуны сайлыйлар алар: “Без бары бер Аллаһка гына гыйбадәт кылачакбыз, Бер Аңа без буйсыначакбыз,”- диләр. **“Без динебезне ачык тотар, биш вакыт намазыбызны иркенләп укыр, уразаларыбызны тыныч күңел белән тота алырдай вакытлар җитәр әле,” - дип өметләнеп, ерак юлларга чыгып китәргә мәҗбүр булалар.**

Көчләп чукындырылган кешеләр арасында милләтләрен, диннәрен саклап калыр өчен генә христиан динен кабул иткән кыяфәт ясаучылар да булган. Алар арасында үлем куркынычы белән дин кабул итәргә мәҗбүр ителүчеләр дә бар.

Мондый көчләп чукындыруга дучар булган бер авыл халкы вакыйгасын тыңлагыз әле. Аны мәшһүр галимебез **Ризэтдин Фәхреддин хәзрәтләре бәян итә:** Әчтерхан өлкәсендә Кече Чапурино дигән бер авыл бар. 1646 нчы елда бу авыл халкын христианнар дип язып куялар. Алар диннәрен саклап калыр өчен, христиан исеменнән качып, Казан губернасыннан бу якларга күченеп килгән булалар. Әмма, кызганычка каршы, килеп җитүгә аларны шунда ук чиркәүгә беркетәләр, һәм һәр атна саен чиркәүгә йөрергә мәҗбүр итәләр. Моңа карамастан, алар биш вакыт намазларын, уразаларын калдырмыйлар. Алар Аллаһка өметләнеп, кача-поса гыйбадәтләрен дәвам итәләр. Хакимиятнең басымы әз генә кимү белән, авыл халкы чиркәүгә йөрүдән туктый, үз динен тота башлый. Басым арту белән аларны тагын чукынырга мәҗбүр итәләр. Һәм, ниһаять, 1845 нче елда Чапурино халкы гомумән чиркәүгә йөрүдән туктый. Бу хәлне төзәтеп, кире христиан диненә кешеләрне кертү өчен баш чиркәү аларга ике попны җибәрә. Ничаклы үгетләп тә, куркытып та поплар үз максатларына ирешә алмыйлар. Чапурино халкы үз динендә нык тора. Бер ел буе үгетләп тә христиан диненә кайтара алмагач, 1846 нчы елда бу халыкны үгетләп кенә христиан диненә кертеп булмый дип рапорт язалар. Шуннан соң Чапурино **мөселманнарына** берсеннән-берсе авыр сынаулар килә. **Аларны кулга алып, сөргенгә сөрәләр, балаларны аналарыннан көчләп аерып, монастырьларга җибәрәләр. Хатыннар ирләрсез кала, күпләрне төрмәләргә ябалар, балалар әтисез үсә. Болар бары тик халыкны Исламнан чыгару өчен эшләнә. Нәтиҗәдә, 1849 нчы елның 20 нче апрелендә министрга бөтенесе христиан диненә кире кайтты дигән хат җибәрәләр.** Бәлки, алар бу сүзләрне көчләп әйтергә һәм имза куярга мәҗбүр булганнардыр, ләкин халыкның йөрәгендәге иманны какшата алмаганнар.

**Менә шуннан соң тагын бер сынау килә аларга - аларны башка мөселманнар белән аралашудан тыялар. Кырык елдан артык халык имамнарыннан аерылган хәлдә була, имамнары дәүләтнең катгый рәвештә тыелуы аркасында халыкка хезмәт итә алмый. Туган сабыйларга исем бирердәй, никах укырдай, бәйрәм намазлары үткәрердәй кеше калмый. Боларның барысы тыела.** Халык бу дәвердә үз кавеме эчендә булдыра алганча Исламны тота, **шушы гамәлләрне булдыра алганча үтәргә тырыша.**

Шуннан соң 1849 нчы елда алар **инде ничәнче тапкыр** министрга: “Без хакыйкатьтә мөселманнар һәм беркайчан да христиан динен тотканыбыз булмады!”- дип хат юллыйлар. Әмма аларны беркем ишетергә теләми һәм **Чапурино мөселманнары** шулай кимсетелеп яшәргә мәҗбүр булалар.

**Әмма без беләбез - һәр авырлык артыннан җиңеллек килә. Аллаһы Тәгалә әйтә: “Һәр авырлыктан соң җиңеллек килә.” Ниһаять, 1905 нче елда сабырлыклары өчен алар әҗерен алалар - ачык рәвештә ислам динен тотарга рөхсәт итәләр аларга.** Бары 1905 нче елның 17 апрелендә генә, манифестка кул куелганнан соң гына, аларның мөселман икәнен таныйлар. Аллаһу Әкбәр! Бары ике йөз ел түзгәннән соң гына аларны мөселман дип атыйлар. **Ике йөз ел буена алар диннәрен бик кадерләп саклыйлар. Күпме буыннар: “Эх, кайчан динебезне качырмыйча, иркенләп тотарбыз микән?”- дип өметләнеп яшәгәннәр. Әмма бу бәхетле вакытларга җитә алмыйча якты дөнья белән хушлашканнар. Алар Аллаһка тугры булалар, Аллаһ та аларга тугры. Аллаһы Тәгалә әйтә:** “Әй, иман китергәннәр, Аллаһтан куркыгыз һәм тугры булыгыз.”

Карагыз, күпме авырлыклар, корбаннар китереп алар безгә динебезне саклап калганнар. Ә без нишлибез? Менә алар безнең каршыбызда торалар: “Бездән соң сез кемгә гыйбадәт кылачаксыз?”- дип сорасалар, ни дип җавап бирербез? Без аларның өметләрен акларбызмы?

Алар үлем куркынычы астында яшертен намаз укыганнар, ә ни өчен безгә иртәнге намазга тору бик авыр? Алар муллалар булмауга карамастан, үзлегеннән белем алганнар, белгәннәренә калганнарны өйрәткәннәр. Ә ни өчен без һаман Аллаһ китабын укырга өйрәнмибез? Алар сөрелгән, әзәрлекләнгән хәлдә булуларына карамастан, бер-берсенә нык тотынганнар, ә без һаман дошманлашабыз. Бер-беребездән гаеп табарга тырышабыз. Әҗәлебез якадан тотканда балаларыбызга нинди динне калдырабыз без? Алар безне нинди итеп истә калдырырлар? Батырлар итепме? Әллә көне буе телевизор караучылар итепме, хәрәм тыңлаучылар, сөйләүчеләр, хәрәм кылучылар итеп истә калдырырлармы? Динен бу дөньяга алыштыручы итепме? Мондый эпизодлар, чорлар, моментлар безнең тормышыбызда аз түгел. **Исегезгә төшерегез, әле күптән түгел генә, коммунистлар чорында, дин тыелган чакларда, безнең әби-бабайларыбыз диннәрен саклап калырга тырышканнар. Дин тыелган чакта да, алар яшерен рәвештә өйләрендә кача-поса намазын да укыганнар, Коръәнне дә калдырмаганнар. Кайберәүләр хәтта туган көн үткәрәбез дигән булып, Коръән ашлары үткәргән. Карагыз, алар ничек тырышканнар, ә без алар өчен бүген дога кылабызмы?**

Аллаһ Тәгалә Коръәндә әйтә:

“Бу халык инде юк. Алар ирешкәннәрен алырлар, ә сез үзегезнекен алырсыз. Һәм алар кылганнары өчен сез җавап бирмәссез.”

Бу кешеләр фани дөньядагы сынауларын үттеләр, һәм алар гамәлләре өчен тиешен алырлар.

Ә хәзер алдагы буыннар калдырганны саклар өчен безнең чират җитте. Үзебезнең динебезне, иманыбызны, илебезне, татар телебезне саклыйк. Тиздән безнең дә балаларыбыздан: «Миннән соң кемгә гыйбадәт кылачаксыз?» дип сорар көнебез килеп җитәр.

**Йә Аллаһ, бу дөнья белән хушлашканчы, әҗәлебез килеп җиткәнче, балаларыбызның динебезгә тугрылыклы булып калуларын, аларның ныклап Исламга ябышуларын күреп куанырга насыйп ит безгә.**

**Әбүбәкер хәзрәт Әбдиев, Чаллының**
**“Тәүбә” мәчете имам-хатыйбы.**

# Сорау вә җавап

**Әссәләмегаләйкүм, мөхтәрәм “Ислам нуры” газетасы хезмәткәрләре!**

**Түбәндәге сорауларыма җавап ала алсам бик тә рәхмәтле булыр идем.**

**1. Мәхрәм турында. “Ниса” сүрәсе, 23 аять: “Апаларыгызны, туталарыгызны, кардәшләрегезнең кызларын никахлау хәрам.” Олы кыз туганнарны кайберәүләр”апа”ди, ә кайберәүләр “түти” ди. ”Кардәшләрегезнең кызлары” дигәндә, без бит бернечә буын туганнарны да, кода-кодагыйларны да “кардәш” дибез. Әтиеңнең яки әниеңнең туганының кызы мәхрәмме? Килен дә мәхрәм.**

**Әле безнең хатыннар да (миңа 86 яшь) биатадан тел яшерәләр иде (хәзер андыйларны күргән юк). Мәсәлән, мәхрәм белән кул биреп сәламләшергә ярый, ә килен белән ничек була инде?**

**2. Пәйгамбәребез саллалаһу галәйһи вә сәлләм 63 ел яшәгән. Ул милади белән микән? Әллә һиҗри, яки үзе яшәгән вакыттагы календарь беләнме?**

**Элеккеге пәйгамбәрләрнең бик озак яшәүләре турында әйтелә. Мәсәлән, Нух (г.с.) 950 ел яшәгән диелә. Нинди календарь белән санала икән ул?**

Сезгә уңышлар теләп,

**Салих Зиннәтов**
**Зәй районы, Аксар авылы**.

1. Коръәндә мәхрәмнәр (өйләнешергә тыелган якын кардәшләр) турында әйтелгән. Бертуган апа һәм сеңелләрнең кызларына никахлашу тыела. Ә атаның бертуган кыз туганнарының кызлары икетуган була, син аларга мәхрәм түгел. Ягъни аларга никахлашу мөмкин. Шулай ук ананың бертуган кыз туганарының кызлары икетуган була инде һәм аларга да никахлашу ярый. Шуңа күрә син аларга мәхрәм түгел (ягъни нәмахрам буласың), алар белән бергә-бер калу ярамый. Әмма атаның, ананың кыз туганнарына син мәхрәм буласың.

Мәхрәм белән кул бирешеп күрешергә дигәндә, мәхрәмнәр төрле була. Мәңгелек һәм вакытлыча мәхрәмнәр бар. Мәңгелек мәхрәм дигәне ул кан, сөт, никах туганлыгы буенча. Никах туганлыгы буенча дигәне, мәсәлән, синең улың килененең аерса да, ул киленгә биатасы мәхрәм булып кала. Мәңгелек мәхрәмнәр белән кул бирешеп күрешү, сөйләшү рөхсәт ителә. Биата үзенең килене, улларының, оныкларының хатыннары белән кул биреп күрешә ала. Бездә ул гадәт саналмаса да, рөхсәт ителә. Бертуганнарыңның, әйтик, энеләреңнең хатыннары килен булса да, аларга син вакытлыча мәхрәм, алар белән кул бирешеп күрешү, бергә-бер калу ярамый. Биатадан тел яшерү дигәне ул безнең әдәп буенча. Биатасы белән килен сөйләшә ала. Хәтта килене улыннан аерылса да, биатасы аңа үлгәнчегә хәтле мәхрәм була. Хатын-кыз үзенең биатасына беркайчан да никахлана алмый.

2. Һиҗри ел белән санау Хәлифәләр вакытында кертелгән. Пәйгамбәребез (с.г.в.) вакытында ел исәбе милади буенча алып барылган. Пәйгамбәребез (с.г.в.) 570 елны туган, 610 елны аңа пәйгамбәрлек килгән, 633 тә вафат булган дип килә китапларда. Шуңа күрә 63 ел ул милади ел санавы буенча әйтелә. Нух пәйгамбәргә килгәндә, мең ел кешеләргә дәгъвәт кылды, 50 елдан башка дип әйтелә, ягъни 950 ел дингә чакырган була. Бу аның гомер озынлыгы түгел. Ләкин яшь саны ул заманда саналган буенча. Төгәл генә ул инде билгеле түгел.

**Әссәләмү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!**

**Хөрмәтле “Ислам нуры” газетасын нәшер итүче дин кардәшләребез, минем сезгә бернечә соравым бар иде:**

**1. Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча намаз укыганда тәсбих тарту өйлә намазында кайчан башкарылырга тиеш?**

**2. Соңгы вакытларда мөселман кардәшләребез арасында бернечә хатын белән тору гадәткә керә бара. Алар моны пәйгамбәребез кушуы буенча эшлибез диләр. Беренче хатын риза булмаганда, икенче, өченче хатынга өйләнергә ярыймы? Газетагыз аша җавап бирсәгез иде.**

Сезгә зур ихтирам белән

**Сарманнан Өнип Гамиров**

1. Безнең мәзһәб буенча өйлә намазында башта 4 рәкәгать сөннәт укыла. аннары соң камәт әйтелеп 4 рәкәгать фарыз башкарыла. Аннан соң 2 рәкәгать сөннәт намазы. Шуннан соң тәсбихләр, зекерләр әйтелә, дога кылына. Ягъни Хәнәфи мәзһәбендә тәсбих-зекерләр өйлә намазында ике рәкәгать сөннәт намазыннан соң башкарыла. Шушы тәртиптә башкару яхшырак санала, мәҗбүри дигән әйбер юк.

2. Никахлашу шартларының беренчесе - ике якның да мөселман булулары. Икенчесе – ир һәм хатынның ризалыгы, риза булып өйләнешүләре. Ризалык үткән заманда әйтелергә - риза булып бардым, риза булып алдым дигән сүзләр булырга тиеш. Һәм өченчесе ике акыллы бәлигъ ир мөселманның (яки бер ир һәм ике хатын кызның) шаһит булуы, ягъни никах килешүендә катнашуы. Шушы шартлар үтәлсә, никах дөрес була. Ә мәһер ул никах шартына керми, мәһер сөйләшенмәсә дә, бирелмәсә дә никах дөрес була. Ләкин инде никах килешүе тәмамланганнан соң мәһерне түләү ир өчен фарыз булып кала.

Бернечә хатын алганда алдагы хатыннарның ризалыгы кирәк дигән кагыйдә шәригатьтә юк. Ул никах шартларына керми. Шуңа күрә никахланучыларның үзләренең ризалыгы гына кирәк. Әлбәттә, никах килешүендә кыз ягыннан вәлие, туганы катнашса яхшырак. Ләкин анысы да шарт булып тормый. Бәлигъ мөселман хатын-кызы үзе риза булып кияүгә чыкса, ул никах дөрес була.

**Әссәләмү галәйкүм, хөрмәтле редакция!**

**Безнең бернечә соравыбыз бар иде:**

**1. Бер генә булса да Коръән аятен белеп инкяр иткән кеше кяфергә әйләнә диләр. Шул кешегә оеп намаз уку дөрес буламы?**

**2. Намаз укыганда бер рәкәгатьтә ике сүрә укысаң, икенче сүрәне башлаганда бисмилләһ әйтеләме?**

**3. Үз мәхәлләңдә кеше җитмәү сәбәпле җомга намазы укылмаса башка мәчеткә җомгага бару мәкрүһ булмыймы (шул исәптән муллага да)?**

**Алдан ук сезгә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре булсын!**

**Сарман авылы, Хаҗиев Мөдәрис**

1. Әгәр кеше белә торып, аңлап Коръән аятен түгел, гомумән Коръәннең бер сүзен генә инкяр итсә дә, Аллаһы Тәгаләнең сүзе түгел дисә, яисә кабул итмим, дөрес түгел, дип әйтсә, бу кеше мөртәт була. Әгәр ул чынлап та шундый кеше булса, аның артында оеп намаз уку дөрес түгел. Әгәр ул тәүбә итсә, шәһәдәт кәлимәсен әйтеп кире Исламга кайтса, ул мөселманга әйләнә. Әгәр шулай эшләмәсә ул мөртәт булып кала.

2. Бездә - Хәнәфи мәзһәбендә Фатиха сүрәсен укыганнан соң икенче сүрәне кушканда бисмиллә әйтелми, ул Фатиха сүрәсе алдыннан әйтелә.

3. Әгәр инде кеше мәхәлләгә имам итеп билгеләнгән икән, ул үз мәчетендә укырга тиеш. Әгәр инде, мәсәлән, авылда берничә мәчет булса, һәр мәчеткә дә кешеләр җыелмаса, үзләре килешеп бер мәчеттә генә укыйлар – аерым билгеләнгән Җәмигъ мәчетләре була. Мөселман илләрендә җомга барлык мәчетләрдә дә укылмый. Бу очракта имамның башка мәчеткә китүен мәкрүһ дип әйтеп булмый. Әмма инде, кешеләр килмәс әле, дип, ягъни төгәл белмичә җомганы башка мәчеттә уку - ул мәкрүһ. Чөнки кешеләрнең җыелмаганлыгын мәчеткә килмичә белеп булмый. Имам мәчеткә килсә, халык җыелмаса, имам башка мәчеткә барырга өлгерми торган булса, мондый вакытта ул өйлә намазы укырга тиеш.

*Укучыларыбыз сорауларына җавапны шәригать белгече*
*Рәфыйк хәзрәт Миннеәхмәт бирде.*

## Язгы уйланулар

Яз айлары, янгыр ява -
Карлар эри янгыр суыннан;
Шул карларга карап уйга калам,
Бу табигать гажәп корылган.

Раббым бар итә һәр нәрсәне
Һәм тәмамлый аны сонынннан;
Тәмамланмый минем тормыш кына,
Күчү генә була дөньядан.

Ахирәттә чын яшәеш көтә,
Сынау дөньясы тәмамланган;
Тик, Раббым, кичер гөнаһларым -
Һәр гамәлем инде язылган.

Һәрбер көнем, әйткән сүзем өчен,
Жавап бирү була яңадан;
Изгелегем унга тапкырланса,
Һәр гөнаһым күрәм яңадан.

Сөенеп ачсам иде китабымны,
– Укыгыз, - дип – ниләр язылган;
Белдем, әзерләндем бу тормышка,
Тырышлыгым хәерлегә булган.

Ышандым мин аять, хәдисләргә,
Дөнья - уен! Вакыт саналган!
Ашыгыгыз изге гамәлләргә -
Ахыр көнебез билгеләп куелган!

Шушы көндә ишетәсем килә,
Фәрештәнең матур сүзеннән:
“Кайт Раббын ризалыгына бүген,
АЛЛАһ ТӘГАЛӘ разый синнән!”

Күрәсем килә Раббым Синен Йөзең
Ул бит югары дәрәҗәдән!
Нурлар сибеп төрле якларымнан
Күрешәсем килә Синең белән.

Рәсүлебез, аңа АЛЛАҺнын салаваты,
Сәламнәре булсын чын күңелемнән;
Каршы алсын иде мине анда,
Дустым диеп, кочып инемнән.

Жәннәтләрдә бергә булсак иде
Шәрап эчеп тулы касәләрдән;
Сөендерсен иде хур кызлары,
Энҗе-мәрҗән кебек сибелгән.

Бу хыяллар һәр мөэминдә бардыр,
Инанса әгәр чын күңеленнән.
Тик киләчәк бу көн! Мин ышанам!
Бары буласы иде шул төркемнән!

**Илназ хәзрәт Яхин,**
**Чаллының “Ихлас” мәчете имам-хатыйбы**.

# Намаз вакытлары

| Милади апрель | Көн исеме | Рәҗәб, Шәгбан | Иртәнге намаз: Таң беленә | | | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла | | | Кояш чыга | | | Зәвал | | | Өйлә | | | Икенде | | | Ахшам | | | Ястү | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан |
| 1 | Шм | 4 | 04.39 | 02.48 | 03.01 | 05.18 | 03.32 | 03.45 | 06.48 | 05.02 | 05.15 | 13.19 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.44 | 15.58 | 16.11 | 19.51 | 18.07 | 18.20 | 21.37 | 19.55 | 20.09 |
| 2 | Як | 5 | 04.35 | 02.45 | 02.58 | 05.16 | 03.30 | 03.43 | 06.46 | 05.00 | 05.13 | 13.19 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.45 | 15.59 | 16.12 | 19.53 | 18.09 | 18.22 | 21.39 | 19.58 | 20.11 |
| 3 | Дш | 6 | 04.32 | 02.41 | 02.54 | 05.13 | 03.27 | 03.40 | 06.43 | 04.57 | 05.10 | 13.19 | 11.33 | 11.46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.47 | 16.01 | 16.14 | 19.55 | 18.11 | 18.24 | 21.42 | 20.01 | 20.14 |
| 4 | Сш | 7 | 04.29 | 02.38 | 02.51 | 05.11 | 03.24 | 03.37 | 06.41 | 04.54 | 05.07 | 13.18 | 11.33 | 11.46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.48 | 16.02 | 16.15 | 19.57 | 18.13 | 18.26 | 21.44 | 20.03 | 20.17 |
| 5 | Чш | 8 | 04.25 | 02.34 | 02.47 | 05.08 | 03.22 | 03.35 | 06.38 | 04.52 | 05.05 | 13.18 | 11.33 | 11.46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.49 | 16.04 | 16.17 | 19.59 | 18.15 | 18.28 | 21.47 | 20.06 | 20.19 |
| 6 | Пж | 9 | 04.22 | 02.31 | 02.44 | 05.06 | 03.19 | 03.32 | 06.36 | 04.49 | 05.02 | 13.18 | 11.32 | 11.46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.51 | 16.05 | 16.18 | 20.01 | 18.17 | 18.30 | 21.49 | 20.09 | 20.22 |
| 7 | Жм | 10 | 04.19 | 02.27 | 02.40 | 05.03 | 03.17 | 03.30 | 06.33 | 04.47 | 05.00 | 13.17 | 11.32 | 11.45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.52 | 16.07 | 16.20 | 20.03 | 18.19 | 18.32 | 21.52 | 20.11 | 20.25 |
| 8 | Шм | 11 | 04.15 | 02.23 | 02.36 | 05.01 | 03.14 | 03.27 | 06.31 | 04.44 | 04.57 | 13.17 | 11.32 | 11.45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.54 | 16.08 | 16.21 | 20.05 | 18.21 | 18.34 | 21.54 | 20.14 | 20.28 |
| 9 | Як | 12 | 04.12 | 02.20 | 02.32 | 04.58 | 03.11 | 03.24 | 06.28 | 04.41 | 04.54 | 13.17 | 11.32 | 11.45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.55 | 16.09 | 16.23 | 20.07 | 18.23 | 18.36 | 21.57 | 20.17 | 20.30 |
| 10 | Дш | 13 | 04.08 | 02.16 | 02.29 | 04.56 | 03.09 | 03.22 | 06.26 | 04.39 | 04.52 | 13.17 | 11.31 | 11.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.56 | 16.11 | 16.24 | 20.09 | 18.25 | 18.38 | 22.00 | 20.20 | 20.33 |
| 11 | Сш | 14 | 04.04 | 02.12 | 02.25 | 04.54 | 03.06 | 03.19 | 06.24 | 04.36 | 04.49 | 13.16 | 11.31 | 11.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.58 | 16.12 | 16.25 | 20.11 | 18.27 | 18.40 | 22.02 | 20.23 | 20.36 |
| 12 | Чш | 15 | 04.01 | 02.08 | 02.21 | 04.51 | 03.04 | 03.17 | 06.21 | 04.34 | 04.47 | 13.16 | 11.31 | 11.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.59 | 16.14 | 16.27 | 20.12 | 18.29 | 18.42 | 22.05 | 20.26 | 20.39 |
| 13 | Пж | 16 | 03.57 | 02.04 | 02.17 | 04.49 | 03.01 | 03.14 | 06.19 | 04.31 | 04.44 | 13.16 | 11.31 | 11.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.00 | 16.15 | 16.28 | 20.14 | 18.31 | 18.44 | 22.08 | 20.28 | 20.42 |
| 14 | Жм | 17 | 03.53 | 02.00 | 02.13 | 04.46 | 02.59 | 03.12 | 06.16 | 04.29 | 04.42 | 13.16 | 11.30 | 11.43 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.02 | 16.16 | 16.30 | 20.16 | 18.33 | 18.46 | 22.11 | 20.31 | 20.45 |
| 15 | Шм | 18 | 03.49 | 01.56 | 02.09 | 04.44 | 02.56 | 03.09 | 06.14 | 04.26 | 04.39 | 13.15 | 11.30 | 11.43 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.03 | 16.18 | 16.31 | 20.18 | 18.35 | 18.48 | 22.13 | 20.35 | 20.48 |
| 16 | Як | 19 | 03.46 | 01.52 | 02.05 | 04.41 | 02.54 | 03.07 | 06.11 | 04.24 | 04.37 | 13.15 | 11.30 | 11.43 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.04 | 16.19 | 16.32 | 20.20 | 18.37 | 18.50 | 22.16 | 20.38 | 20.51 |
| 17 | Дш | 20 | 03.42 | 01.48 | 02.00 | 04.39 | 02.51 | 03.04 | 06.09 | 04.21 | 04.34 | 13.15 | 11.30 | 11.43 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.05 | 16.21 | 16.34 | 20.22 | 18.39 | 18.52 | 22.19 | 20.41 | 20.54 |
| 18 | Сш | 21 | 03.38 | 01.44 | 01.56 | 04.37 | 02.49 | 03.02 | 06.07 | 04.19 | 04.32 | 13.15 | 11.29 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.07 | 16.22 | 16.35 | 20.24 | 18.41 | 18.54 | 22.22 | 20.44 | 20.57 |
| 19 | Чш | 22 | 03.34 | 01.39 | 01.52 | 04.34 | 02.46 | 02.59 | 06.04 | 04.16 | 04.29 | 13.14 | 11.29 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.08 | 16.23 | 16.36 | 20.26 | 18.43 | 18.56 | 22.25 | 20.47 | 21.01 |
| 20 | Пж | 23 | 03.30 | 01.35 | 01.47 | 04.32 | 02.44 | 02.57 | 06.02 | 04.14 | 04.27 | 13.14 | 11.29 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.09 | 16.25 | 16.38 | 20.28 | 18.45 | 18.58 | 22.28 | 20.50 | 21.04 |
| 21 | Жм | 24 | 03.26 | 01.30 | 01.43 | 04.29 | 02.41 | 02.54 | 05.59 | 04.11 | 04.24 | 13.14 | 11.29 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.11 | 16.26 | 16.39 | 20.30 | 18.47 | 19.00 | 22.31 | 20.54 | 21.07 |
| 22 | Шм | 25 | 03.21 | 01.25 | 01.38 | 04.27 | 02.39 | 02.52 | 05.57 | 04.09 | 04.22 | 13.14 | 11.28 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.12 | 16.27 | 16.40 | 20.32 | 18.49 | 19.03 | 22.34 | 20.57 | 21.11 |
| 23 | Як | 26 | 03.17 | 01.21 | 01.33 | 04.25 | 02.37 | 02.50 | 05.55 | 04.07 | 04.20 | 13.14 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.13 | 16.28 | 16.42 | 20.34 | 18.51 | 19.05 | 22.38 | 21.00 | 21.14 |
| 24 | Дш | 27 | 03.13 | 01.16 | 01.28 | 04.23 | 02.34 | 02.47 | 05.53 | 04.04 | 04.17 | 13.13 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.14 | 16.30 | 16.43 | 20.36 | 18.53 | 19.07 | 22.41 | 21.04 | 21.17 |
| 25 | Сш | 28 | 03.08 | 01.10 | 01.23 | 04.20 | 02.32 | 02.45 | 05.50 | 04.02 | 04.15 | 13.13 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.16 | 16.31 | 16.44 | 20.38 | 18.55 | 19.09 | 22.44 | 21.08 | 21.21 |
| 26 | Чш | 29 | 03.03 | 01.05 | 01.17 | 04.18 | 02.30 | 02.43 | 05.48 | 04.00 | 04.13 | 13.13 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.17 | 16.32 | 16.45 | 20.40 | 18.57 | 19.11 | 22.47 | 21.11 | 21.25 |
| 27 | Пж | 1 | 02.59 | 00.59 | 01.12 | 04.16 | 02.27 | 02.40 | 05.46 | 03.57 | 04.10 | 13.13 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.18 | 16.34 | 16.47 | 20.41 | 18.59 | 19.13 | 22.51 | 21.15 | 21.28 |
| 28 | Жм | 2 | 02.54 | 00.54 | 01.06 | 04.14 | 02.25 | 02.38 | 05.44 | 03.55 | 04.08 | 13.13 | 11.27 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.19 | 16.35 | 16.48 | 20.43 | 19.01 | 19.15 | 22.54 | 21.19 | 21.32 |
| 29 | Шм | 3 | 02.48 | 00.47 | 01.00 | 04.11 | 02.23 | 02.36 | 05.41 | 03.53 | 04.06 | 13.13 | 11.27 | 11.40 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.20 | 16.36 | 16.49 | 20.45 | 19.03 | 19.17 | 22.58 | 21.23 | 21.36 |
| 30 | Як | 4 | 02.43 | 00.41 | 00.53 | 04.09 | 02.20 | 02.33 | 05.39 | 03.50 | 04.03 | 13.13 | 11.27 | 11.40 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.22 | 16.37 | 16.50 | 20.47 | 19.05 | 19.19 | 23.00 | 21.26 | 21.40 |

# Коръән хәтем кылабыз

Татарстандагы барча мәчетләрдәге кебек Чаллы шәһәренең “Ак мәчете”ндә дә якшәмбе укулары октябрь аенда башлана. Укучылар бик күп: 7 яшьтән 80 яшькә кадәр. Ул гына да түгел, февральнең беренче якшәмбесендә өстәмә төстә яңа уку төркемнәре оештырыла. Мин үзем дә шушы мәчеттә якшәмбе мәктәбендә 15 ел дәресләр бирдем.

Минем башымда күптәннән уй йөри иде — мәчеттә Коръән хәтем кылу турында. Чөнки хаҗда булганда белдем: Мәккә шәһәрендә тәүлек буе ел дәвамында бертуктаусыз Коръән хәтем кылына. Шушы уй белән Коръән укучылар белән сөйләшеп мәчеттә Коръән хәтем кылырга булдык. Әлхәмделилләһи, 2016 елның октябрь аеннан бирле Коръән хәтем кылабыз. Бик теләп түбәндәге мөселманнар бу саваплы гамәлне үтиләр:

1. Фазыл Ганиев
2. Вазых Дәүләтгәрәев
3. Флюр Галимуллин
4. Мурат Шәмсиев
5. Раил Рамазанов
6. Динар Хәдиев
7. Габдрахман Музафаров

Башка мәчетләр дә бу саваплы эшкә кушылсалар иманыбыз тагын да ныгыр, тормышыбыз исә иминләрәк, бәрәкәтлерәк булыр иде.

**Флюр Галимуллин**



**Рәсемдә:** (сулдан уңга) Динар Хәдиев, Флюр Галимуллин, Фазыл Ганиев Коръән хәтем кылу вакытында.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррире**
**Хәлил ШӘРИФ**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен: e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җаваплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1300.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан саклануларыгыз дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды: график буенча 20 март 16 сәг., фактта 20 март 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**